КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2020 ел, 05 февраль г.Казань № б-225

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 26 декабрь, б-3598 нче боерыгы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 7 ноябрь, б-983 нче карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган 2021 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасында мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру чаралары планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

14 пунктның 4 графасында «30 март» сүзләрен «15 март» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «16. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының рәсми сайтында www.prav.tatarstan.ru мәҗбүри хисап урнаштыруны оештыру | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының рәсми сайтында www.prav.tatarstan.ru мәгълүмат | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рекомендацияләрен алганнан соң 10 көн эчендә (ел саен) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының социаль үсеш идарәсе»; |

түбәндәге эчтәлекле $16^1$ пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «$16^1$. | Тиешле оешмалар-ның эшен оештыруны яхшырту буенча Татарстан Республикасы Президентына | мәҗбүри гавами хисап, Татарстан Республикасы Дәү-ләт Советы карары, анда тиешле оешма-ларның эшен оеш- | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рекомендацияләрен алганнан соң биш көн эчендә (ел саен) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының социаль үсеш идарәсе»; |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тәкъдимнамәләрне үз эченә алган мәҗбүри хисап һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына җибәрү | тыруны яхшырту буенча Татарстан Республикасы Президентына тәкъдимнәр бар | | |

түбәндәге эчтәлекле $16^2$ пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «$16^2$. | Татарстан Республикасы Президентына тиешле оешмаларның эшен оештыруны яхшырту буенча тәкъдимнәр үз эченә алган мәҗбүри хисап һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарларын www.bus.gov.ru рәсми сайтта урнаштыруны оештыру | www.bus.gov.ru рәсми сайттагы мәгълүмат | Татарстан Респуб-ликасы Министрлар Кабинеты Аппаратының социаль үсеш идарәсеннән алынганнан соң биш көн эчендә (ел саен) | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы»; |

17 пунктның 4 графасында «25 март» сүзләрен «5 март» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин